РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

РЕШЕНИЕ КАРАР

17 декабрь 2021 ел №25

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 23, 26 статьялары, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында кодексы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Кукмара шәһәре Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында Нигезләмәне расларга.

2. Кукмара поселок Советының «Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны һәм муниципаль хезмәткәрләргә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турында» Кукмара поселок Советының 2014 елның 30 июлендәге 15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 19 апрелендәге 8 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Кукмара шәһәре мэры С.Д. Димитриев

Кукмара шәһәре Советының 2021
елның17 декабрендәге 25-нче
номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында Нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү (алга таба – бер тапкыр бирелә торган түләү) тәртибе турында әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 23, 26 статьялары, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниццципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнде.

2. Муниципаль хезмәткәргә, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәттән азат ителгәндә, тиешле елда дәвамлылыгы әлеге Нигезләмәнең кушымтасы нигезендә билгеләнә торган муниципаль хезмәт стажы булса, эштән азат ителгән көнгә биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча аның айлык кереме ун тапкыр арттырылган күләмдә һәм муниципаль хезмәтнең алдагы һәр тулы елы өчен – өстәмә 0,5 акчалата кереме кадәр, әмма муниципаль хезмәткәрнең акчалата кереме ун размердан да артмаган күләмдә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү түләнә. Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат иткән көнгә билгеләнә.

3. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә, «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә, муниципаль хезмәткәрнең гаепле гамәлләренә бәйле эштән азат ителүдән тыш, картлык буенча хезмәт пенсиясе алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч яисә инвалидлык буенча һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда пенсия билгеләнгәндә, муниципаль хезмәттән азат ителү аңлашыла.

4. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата керем составына кертелә:

- вазыйфаи оклад;
- класслы чин өчен өстәмә түләү;
- муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә.

5. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турындагы карар эш бирүче (яллаучы вәкиле) тарафыннан кабул ителә, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү турында карар кабул ителү белән бер үк вакытта рәсмиләштерелә.

6. Бер тапкыр бирелә торган түләү муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгәнче хезмәт итә торган органның эш бирүчесе (яллаучы вәкиле) тарафыннан муниципаль хезмәткәр эштән киткәннән соң бер айдан да соңга калмыйча түләнә.

7. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, бер тапкыр бирелә торган түләү бер тапкыр түләнә. тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыккач һәм аннан соң муниципаль хезмәт туктатылгач, гражданин муниципаль хезмәткә кергәндә бер тапкыр бирелә торган түләү кабат түләнми.

8. Җирле үзидарә органы, муниципаль хезмәткәр тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә эштән киткәнчегә кадәр 30 календарь көн эчендә, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» Муниципаль казна учреждениесенә (алга таба– Финанс-бюджет палатасы), бер тапкыр бирелә торган түләү күләмен билгеләү өчен, түбәндәге документларны тапшыра:

8.1. пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бирү турында муниципаль хезмәткәрнең гаризасы;

8.2. муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата кереме турында белешмә;

8.3. муниципаль хезмәттәге эш стажы турында җитәкче һәм кадрлар хезмәте раслаган белешмә;

8.4. хезмәт кенәгәсенең һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәнең (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясы) һәм хәрби билетның кадрлар хезмәте раслаган күчермәләре;

8.5. классны чин бирү, муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата кереме составына керүче вазыйфаи окладка өстәмәләр билгеләү турында күрсәтмәләрдән өземтә;

8.6. дисциплинар җәза булмау турында белешмә.

9. Бер тапкыр бирелә торган түләү түләнми:

9.1. эштән азат ителгән вакытка дисциплинар җәзасы алынмаган муниципаль хезмәткәргә;

9.2. дәүләт граждан хезмәте турындагы законнар нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган түләү инде түләнгән муниципаль хезмәткәргә.

10. Бер тапкыр бирелә торган түләү хезмәт кенәгәсендә тамга куеп түләнә.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрләргә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында Нигезләмәгә кушымта

**Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү өчен муниципаль хезмәт СТАЖЫ**

| Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү елы | Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажы |
|---|---|
| 2017 | 15 ел 6 ай |
| 2018 | 16 ел |
| 2019 | 16 ел 6 ай |
| 2020 | 17 ел |
| 2021 | 17 ел 6 ай |
| 2022 | 18 ел |
| 2023 | 18 ел 6 ай |
| 2024 | 19 ел |
| 2025 | 19 ел 6 ай |
| 2026 һәм аннан соңгы еллар | 20 ел |